| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЯНГУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢГУЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» ноябрь 2024 ел № 124

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2024 елның 8 августындагы 289-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.6.4 пунктта "66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4.7.10 пунктта "66 статьясындагы 12 өлешендә» сүзләрен «66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 4.9.5 нче пункт түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.5. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге нигезләмәдәге 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) рәсми рәвештә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында(baltasi.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Яңгул авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Яңгул авыл җирлеге Советы башлыгы Р.Р.Гыйльфанов